# Җиңү китергән таныш йөзләр!

Садри Гарәфи улы Гарәфиев



**Хөрмәтле Садри Гарәфи улы!**



Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 70 ел үткән. Хәтер буыннардан буыннарга тапшырылып килә. Хәзер инде Халыкның Бөек Батырлыгы турында сезнең балаларыгыз һәм оныкларыгыз гына түгел, оныкларыгызның балалары да белә.

Дистәләгән еллар буена Бөек Ватан сугышы турында меңләгән китап язылган. Тарихчылар коры фактлар һәм саннарда барлык канкойгыч бәрелешләрнең хронологиясен булдырдылар. Бүген һәркем Сталинград бәрелеше, Ленинград камалышы, Мәскәү өчен, Курск Дугасы һәм Днепрдагы сугышлар кебек истәлекле вакыйгалар турында укый ала. Һәрбер хәрби вакыйга артында миллионлаган солдат һәм офицер, генерал һәм маршал, гади санитаркалар һәм тәҗрибәле хәрби хирургларның язмышы ята.

Һәр ветеранның үз сугышы, үз тарихы, үз җиңүе.Ул хәтер папка, альбом, хәрби фотографияләр һәм хатларда һәм, билгеле, күңелләрдә саклана.

Сугышта катнашкан һәркемнең батырлыгы мәңге истә сакланырга лаек. Һәм без – Сезнең балаларыгыз, оныкларыгыз, оныкларыгызның балалары, Сезнең сугышны һәм Сезнең Җиңүне аерым бер китапта бастыруны үзебезнең бурычыбыз дип саныйбыз.

Бу китап Бөек Ватан сугышының чын каһарманы Сезнең турыда. Үз-үзен жәлләмичә, яшәү турында да, үлем турында да уйламыйча оккупацияләнгән шәһәрләрне азат иткән, Җиңүгә үзеннән бәһасез өлеш керткән кеше турында. Ватанны фидакарь саклаган, илебезгә генә түгел бөтен планетага тынычлык бүләк иткән батыр һәм курку белмәс кеше турында.

Сезнең хатирәләрне укыганда без кешенең шундый шартларга ничек түзүен күз алдына да китерә алмыйбыз. Берөзлексез бомбага тотулар, атышлар, ачлык, салкыннар һәм фашистларның рәхимсезлеге. Бары якыннарыгызга һәм туган җирегезгә булган ярату хисләре Сезгә Җиңү көнен якынайтырга ярдәм иткән!

Бүген без Сезгә шундый ук ярату хисләре белән карыйбыз. Без Сезнең алдыгызда баш иябез.

Мәңгелек дан Сезгә, бөегебез, газизебез Садри Гарәфи улы!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов

## Садри Гарәфи улы Гарәфиев



Садри Гарәфи улы Гарәфиев – ике сугышта: Бөек Ватан һәм Япония белән сугышларда катнаша. Иң югары бүләкләрнең берсе – Кызыл Йолдыз ордены кавалеры белән Берлин операциясе өчен бүләкләнә. Садри Гарәфи улы үзенең батырлыклары турында теләмичә генә сөйли. Сугышта иң зур батырлыкларны җәяүле гаскәрләр эшләде дип саный. Ул бит артиллерия гаскәрләрендә хезмәт иткән. Сугыш вакытында беркайчан да чигенергә туры килмәгәне өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтлемен, ди. Садри Гарәфи улы хезмәт иткән 32 аерым артиллерия дивизионы бары тик атакага гына барган. Баш Командованиенең Аерым куәтле резерв Артиллериясе дошманга һәрвакыт төгәл төбәп ата. Берлин өчен бәрелешләр вакытында аларның дивизионы, башкалар белән беррәттән, Рейхстагка аткан. Җиңүне Садрый Гарәфи улы тар-мар ителгән фашист Германиясенең башкаласында каршылый. Тик Җиңү шатлыгы озакка бармый. 1945 нче елның июнь башында ук ефрейтор Гарәфиев дивизионы Япония белән сугышка җибәрелә.

**_Гадәти булмаган хыяллар_**

*«Мин гомерем буе белем алырга теләдем. "Бишле"гә институт тәмамларга хыялландым. Хәтта икенедер дә! Һөнәри фотограф булырга теләдем. Оста булырга, Казанда, нәшриятта эшләргә, һәрчак вакыйгалар үзәгендә кайнарга. Зур кеше булырга! Гади авыл егетенең менә шундый хыяллары бар иде... Мин бөтен дөньяны шаккаттырырга хыялландым! Тик минем барлык хыялларыма да чынга ашарга насыйп булмады ...»*
















***Минем беренче “Фотокор”***

*«15 яшьтә мин беренче тапкыр кулыма фотоаппарат алдым. Ул вакытта Мари Элдан килгән бик әйбәт укытучыбыз бар иде. Беренче тапкыр әлеге әкәмәтне шул укытучы алып килде. “Фотокор” фотоаппараты. Бик күп иптәшләрем аны кулларында әйләндергәләделәр дә, оныттылар. Әмма мин түгел! Өйдә мин шашынып беттем, шулкадәр фотога төшерергә өйрәнәсем килә иде! Бер тәүлек еладым! Әти-әни мине һичничек аңлый алмадылар - гади балта остасы белән тегүчедән ничек шундый аксөяк малай туган? Фотоаппарат бит 125 сум тора! Шулай да сатып алдылар. Мин өйдә чын-чын фотолаборатория оештырдым. Һәм бер елдан әтигә акчасын кире кайтардым. Авылдагы кешеләрне фотога төшереп, үзем акча эшли башладым».*

**«Фотокор №1» (еш кына — «Фотокор») − 1930-1940 нчы еллардагы пластиналы җыелма совет фотоаппараты. Алды этелеп куела, икеләтелгән күрекле, турыпочмаклы 9х12см форматындагы универсаль камералы була. Беренче күпләп җитештерелгән совет фотоаппараты − 11 елга 1 млн экземплярда чыгарыла.**

### *Сугыш якынлашу*

*«Ул вакытта фотога төшерү җитди эш саналмый иде. Шуңа күрә мәктәпне тәмамлагач, мин арматурачы булырга укый башладым. Беркем дә мәҗбүр итмәде – үзем киттем! Ул вакытта 6 ай эчендә эшче һөнәре алырга була иде. ПТУ дан ук мине Йошкар-Олага хәрби завод төзергә җибәрделәр. Бу 1941 нче елның башында булды. Тәүлеккә 12 сәгать эшләдек. Ашарга берни юк диярлек. Без баш очыбызда болытлар куера барганны күреп тордык. Дөньяда сугыш җиле исә иде инде...»*









**_Башланды..._**

*«1941 нче елның 22 нче июне – Мари республикасына нигез салынуга 20 ел тулган көн. Безне, яшь эшчеләрне, бәйрәм демонстрациясенә җибәрделәр. Соңыннан 10 ар метр тукыма бирергә вәгъдә иттеләр. Әни белән сеңелләрем матур күлмәкләр тегәрләр дип куандым. Һәм менә без– ярымач, алҗыган эшчеләр стадионга бәйрәм чыгышы тыңларга киттек. Кешеләрнең кәефләре әйбәт түгел иде. Бар да куркыныч яңалык көтеп яшәделәр. Һәм менә ул килде. Нәкъ көндезге сәгать 12 дә тавышкөчәйткечтән сугыш башлануын хәбәр иттеләр. 10 минут эчендә зур стадион бушап калды. Кешеләр бәйрәмнән туры кибетләргә чират алырга киттеләр. Һава кинәт караңгыланып һәм авырaеп киткән кебек тоелды. Бар яктан “Сугыш... Сугыш... Сугыш...” дип ишетелә иде».*







**_Авылдан беренче булып фронтка_**

*«Йошкар-Олада ашарга дөм бернәрсә калмады. Мин авылга кайттым. Колхозда эшли башладым. 1942 нче елның 13 нче августында чакыру килде. Бетте, кадерлеләрем, мин фронтка китәм! Миңа бит ул вакытта нибары 18 яшь иде! Яшьтәшләрем арасында мин авылдан беренче булып киттем. Минем өлкән тормышым сугыштан башланды. Менә мин - озын, ябык малай - туган нигез бусагасында басып торам һәм, шомланып, кара яшен болытларына карыйм... »*

***Нигә без тылда?***

*«Безнең часть ерак тылда, Шевырялово дигән удмурт авылы янында урнашкан иде. Ул вакытта мин – яңа гына килгән кеше бу зур тимер коралларда күпме куәт яшерелгәнен аңлап та бетермәгәнмен. Аларга карагач кына да күңелдә соклану катыш курку туа иде. Снарядның биеклеге генә дә 1,5 метр һәм ул берүзе 35 килограмм авырлыкта. Әлеге снарядны көпшәгә тыгу өчен 7 кеше кирәк. Нигә без алгы сызыкта түгел? Бу сорау өчен тәҗрибәсез малайны берәү дә әрләмәде. Җавап шушы зур коралның тимере кебек салкын булды – чөнки без Баш Командованиенең резервтагы Аерым Куәтле Артиллерия сугышчылары».*





**Белешмә:**

**Зур һәм аерым куәттәге артиллерия – дошманның тирән оборонасындагы аеруча ныгытылган корылмаларын җимерү һәм әһәмиятле объектларын юк итүгә юнәлдерелгән артиллерия. Аңа, гадәттә, пушкалар, гаубицалар, 175-240 мм калибрлы минометлар кертелә. Берләшмәләр һәм бүлекләр Югары Башкомандованиенең резерв артиллериясенә керә.**

**Баш Командованиянең Резерв Артиллериясенең бурычы һөҗүм вакытында гаскәр артиллериясен сан һәм сыйфат ягыннан көчәйтү була. Шунлыктан аның составына гаскәри артиллериядә булган кораллар да, аеруча куәтле, еракка ата торганнары да керә. Составка шулай ук куәтле минометлар һәм тимер юл җайланмалары керә.**

Садри Гарәфиев 32 нче аерым артиллерия дивизионына билгеләнә.









**Белешмә:**

Бөек Ватан сугышы башланганда ВГК резерв Артиллериясе СССР Коры җир гаскәрләре артиллериясенең 8 % ын тәшкил итә. Аның составында:

– 14 пушка һәм 60 гаубица полкы (шул исәптән 203-мм лы гаубицалы зур куәтле полклар

– танкка каршы 10 артиллерия бригадасы аеруча куәтле аерым дивизионнар (210 мм лы пушкалар, 280 мм лы мортиралар, 203 мм лы һәм 305 мм лы гаубицалар)

– аерым миномет батальоннары

Сугыш барышында аның составына зенит артиллериясе, реактив артиллерия һәм үзйөрешле артиллерия берләшмәләре һәм бүлекләре дә кертелә.

## *Коткаручы чокыр*

*«Мин разведчик- күзәтүче идем. Командование атарга күрсәтмә биргәнче, аңа объект турында тәфсилле мәгълумат кирәк. Ә без кайдан күзәтә идек? Землянкалардан. Кайчак ярты Европада землянка казып бетерәбез дип шаярта идек. Я вахтада торабыз, я казыйбыз. Бөтенләй йокламый идек. Ленинград янында мондый вакыйга булды. Казырга фәрман бирделәр. Мин бар нәрсәдә дә беренче булырга өйрәнгән – тырышып казыдым. Шактый шәп чокыр булды. Шулчак безнең өскә миналар ява башлады. Снарядлар яңгыры диярсең. Күк йөзе бөтенләй күренми. Кем чокырын тирәнрәк казыган, шунда сикереп, котылып калды. Әмма минем бик күп полкташларым бу коточкыч төндә харап булдылар».*










Садри Гарәфиев сугышта вакытта



Садри Гарәфиев фотосы

1944 нче елны Садри Гарәфи улы хезмәт иткән 32 нче аерым артиллерия дивизионы Ленинград фронтына җибәрелә.







Садри Гарәфиев полкташлары белән

**Белешмә:**

Ленинград фронты 1941 нче елның 23 нче августында Төньяк фронтны Карелия һәм Ленинград фронтларына бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Фронт алдына Ленинградка туры юлны ябу һәм шәһәрне саклап калу бурычы куела. 1942 нче ел дәвамында фронт гаскәрләре берничә һөҗүм операциясе үткәрәләр. 1943 нче елның гыйнварында Ленинград һәм Волхов фронты гаскәрләре Ленинград камалышын өзү операциясе үткәрәләр. Шәһәрнең ил белән коры җир аша элемтәсе торгызыла. 1944 нче елда Ленинград фронты Волхов, 2 нче Балтыйк буе фронтлары һәм Балтыйк флоты белән берлектә, Ленинград һәм Новгород янындагы немецларның "Төньяк" армияләр төркемен тар-мар китерә, Ленинградны дошман камалышыннан азат итә.

1945 нче елның гыйнварында Садри Гарәфиев хезмәт иткән дивизия Висло - Одер стратегик һөҗүм операциясендә катнаша. Операция бик ашкынулы бара –совет гаскәрләре 20 тәүлек дәвамында көненә 20 – 30 км алга баралар. Шушы вакыт аралыгында алар дошманның 7 ныгытылган сызыгын һәм 2 эре елганы үтәләр.

***Польша***

*«Безне поляк авылына урнаштырдылар. Мондый хәерчелекне беркайда да очратмаган идек. Үзебез дә бай яшәмәдек, ләкин идәннең тактасыз, коры җир булуын аңарчы күргәнем булмады. Кыр кухнясыннан үзебезгә һәм авыл балаларына ашарга алабыз. Ул мескеннәрнең ашарларына бөтенләй юк иде. Ничек кызганмыйсың аларны? Берничә көн эчендә балалар безгә шулкадәр ияләнделәр, хәтта безнең белән йоклый башладылар, куып та чыгарып булмый!»*








**Белешмә:**

Немец-фашист командованиесе ничек тә булса Польшаны саклап калырга омтыла. Тик немец илбасарлары Совет гаскәрләренең һөҗүм операциясен туктатып кала алмыйлар. Операциянең асылы бер үк вакытта берничә урында көчле һөҗүмнәр белән гитлерчылар оборонасын җимерүдән гыйбарәт була. Бу операциядә төп роль авиациягә һәм авыр артиллериягә йөкләнә. Меңләгән корал, миномет һәм реактив артиллерия җайланмалары дошманга җимергеч һөҗүм ясый.  Германия чикләренә ара торган саен якынлаша бара.

Лозунглар: "Алга, Германиягә!", "Берлинга", "Фашист тоткынлыгына куылган туганнарыбызны коткарыйк!"






**Белешмә:**

Совет Кораллы Көчләренең Варшава-Берлин юнәлешендәге һөҗүменең төп нәтиҗәсе Польшаны азат итү була. Илдә канлы террор өстенлек иткән була. Фашистлар оккупациясенең һәр көнендә 3 мең кеше үтерелә. Польша концлагерьлар челтәре белән каплана, аларда меңәрләгән поляк антифашистлары, совет хәрби тоткыннары һәм Европаның башка илләре халкы үлә.

## С.Г. Гарәфиевнең



«Менә ул фашист оясы – Рейхстаг!»
Садри Гарәфиев фотосы





## сугышчан юлы




Сугышчан юлы:

**Яңавыл – Сарапул – Шевырялово авылы – Ленинград фронты – Карелия муентыгы – Польша – Берлин – Ерак Көнчыгыш (Сунгари елгасы, Харбин шәһәре)**



*Сугышчан хезмәттәшләре*



*Садри Гарәфиев*

Сугышчан батырлыклары өчен С.Г.Гарәфиев ике «Батырлык өчен» медале, «Кызыл Йолдыз» ордены, II дәрәҗә Ватан Сугышы ордены, «Берлинны алган өчен», «Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен», «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән



НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Фамилия, имя и отчество:- ГАРАФИЕВ САДРИ

Звание:- Ефрейтор

Должность, часть:- Разведчик-наблюдатель 32 Отдельного артиллерийского Ордена Кутузова Дивизион Особой Мощности РГК

Предоставляется к награде:- медалью " за отвагу "

Год рождения:- 1925 2. Национальность:- Татар.

3. С какого времени в К.А. 1942 4. Партийность - член ВЛКСМ с

5. Участие в боях-май-декабрь 44 Ленфронт, Декабрь-Март 45 г. 1-й Бел.Фр.

6. Имеет ли ранения и контузии- не имеет.

7. Чем ранее награжден- наград не имеет.

8. Каким РВК призван :- Дуб"язским РВК Тат. АССР

9: Постоянный дом. адрес:- [redacted]



Ефрейтор Гарафиев, находясь на НП во время артиллерийской подготовки 7.3.45 корректировал огонь одного орудия, в результате точной корректировки огнем орудия уничтожено 2 огневые точки и подавлен огонь одной минометной батареи. После артиллерийской подготовки, с продвижением пехоты вперед, Ефр. Гарафиев вместе с командиром взвода управления, выдвигаясь в боевые порядки пехоты, обнаружил две огневые точки противника. Продолжая корректировать огнем орудия, Ефр. Гарафиев, огнем орудия подавил обе огневые точки противника.

Достоин правительственной награды- медали " за отвагу "

16 марта 1945 г.

«Батырлык өчен» медале «Батырлык өчен» медале






## орден һәм медальләре

«Кызыл Йолдыз»
ордены



«Бөек Ватан сугышында
Германияне җиңгән өчен»
медале




II дәрәҗә Ватан Сугышы
ордены




«Японияне
җиңгән өчен»
медале




«Берлинны
алган өчен»
медале



## *Икеләтә шатлык*

*«2 нче майда Берлин гарнизонының тулысынча бирелүен хәбәр иттеләр. Ә минем өчен икеләтә бәйрәм! Күңелем канатлана, җырлыйм да биим. Мин шул дәрәҗәдә канәгать идем, бар да миңа карап шаккаттылар. Безнең взвод командиры каяндыр фотоаппарат тапкан. Трофей. Яңа. Пленкалы. Әкәмәт купшы! Болай гына бирмәде -сәгатькә алмаштырды. Ә миңа аның өчен берни дә кызганыч түгел иде! Ул минем өчен бөтен нәрсә дә иде. Туган өй, газиз авылдашларның елмаюлары, тыныч тормыш турындагы истәлекләр. Ә хәзергә фашистлар Германиясенең башкаласы Берлинның һәлакәтен сурәткә төшереп өлгерергә кирәк иде.»*



«Сугышчан хезмәттәшләре»
Садри Гарәфиев фотосы



*Садри Гарәфиев*



Трофей фотоаппараты

**Белешмә:**

**9 майда Мәскәү вакыты белән 0:43 сәгатьтә генерал-фельдмаршал Вильгельм Кейтель һәм маршал Г.К. Жуков Германиянең берсүзсез капитуляциясе турындагы Актка кул куялар. Дүрт еллык сугыш афәтен тәмамлар өчен көрәшкән совет солдатлары һәм офицерларының батырлыгына таянып уздырылган уңышлы операция кителгән нәтиҗәгә – Җиңүгә китерә.**

1945 нче елның апрелендә Садри Гарәфи улы Гарәфиев Берлин операциясендә катнаша. Разведчик Гарәфиев хезмәт иткән 32 нче аерым артиллерия дивизионының залплары Рейхстагта яңгырый.




*«Бранденбург капкасы»*
*Садри Гарәфиев фотосы*

**Белешмә:**

**Берлин сугышы Совет гаскәрләренең Бөек Ватан сугышындагы соңгы эре масштаблы операциясе була, аның барышында Кызыл Армия сугышчылары Германия башкаласын яулап алалар һәм Европада Икенче Бөтендөнья сугышын җиңү белән тәмамлыйлар. Операция 23 көн – 16 нчы апрельдән 8 нче майга кадәр дәвам итә, бу вакытта Совет гаскәрләре Көнбатышка таба 100-220 км алга китәргә өлгерәләр. Берлин өчен сугыш ике атнага сузыла һәм аеруча аяусыз бара, анда 464 мең совет солдаты һәм офицеры катнаша. Нацистлар Германиясе башкаласын штурмлаганда коралны кызганмыйлар. Маршал Жуков мәгълүматлары буенча, 21 нче апрельдән 2 нче майга кадәр Берлинга артиллерия 1,8 млн тапкыр ата. Шәһәр өстенә барлыгы 36 мең тонна металл ява. Башкала үзәген снарядлары тонна ярым авырлыкта булган ныгытмаларны җимерүче орудиеләр дә утка тота. Берлин өчен сугыш Рейхстагны штурмлау һәм Җиңү Байрагы элү белән тәмамлана.**

***Сугыш дәвам итә***

*«Сугыш бетте. Ләкин бу безгә кагылмый иде. Июнь башында ук безнең дивизияне Ерак Көнчыгышка җибәрделәр. Шулай итеп, мин 2 ел Кытайда хезмәт иттем».*






**Белешмә:**

**СССРның Япония белән сугышка керешәчәге 1945 нче елның 11 нче февралендә Ялта конференциясендә хәл ителә. Анда Советлар Союзы Германия җиңелгәч һәм Европада сугыш тәгәлләнгәч, 2-3 айдан соң союздаш державалар составында Япониягә каршы сугышка керешәчәге карала. Япония АКШ, Бөекбритания һәм Кытайның корал ташларга һәм капитуляция ясарга дигән тәкъдимен кире кага. Шул сәбәпле, 1945 нче елның 8 нче августында СССР Япониягә сугыш игълан итә. Төп өлеше 10 көн - 1945 нче елның 9 – 19 нчы августында барган һөҗүм операциясе нәтиҗәсендә 84 мең япон солдаты һәм офицеры юк ителә, 600 меңгә якыны әсирлеккә алына.**



«Мулин шәһәрендә»
Садри Гарәфиев фотосы



**Мин фотокорреспондент!**

*«Японияне тар-мар иткәннән соң Кытай җирендә җитди сугыш хәрәкәтләре булмады. Миңа сугышсыз тормышка күчеп, башка өлкә белән шөгыльләнергә мөмкинлек туды. Мин округның рәсми булмаган фотокорреспонденты! Теләсә нинди эшкә бик теләп алындым. Булган вакыйгалар турында полиция өчен фотоотчетлар ясадым, шәһәр манзарасын һәм аеруча ошаганы – кешеләрне фотога төшердем. Яраткан эшем табыш та китерде. Өйгә яңа гимнастерка, ялтыравыклы итекләрдән һәм бүләкләр белән кайттым! Туганнар минем шундый җитди булмаган эш – фотога төшереп акча эшләгәнлегемә һичничек ышанмадылар».*












Садри Гарәфиев бу фотоларны
хезмәт итүенең төрле елларында төшергән

## Өйгә!

«1947 нче елның мартында мин өйгә кайттым. Бераз авылның газиз һавасын сулаганнан соң Казанны яуларга китү иде планым. Тик әни тыныч, ләкин катгый итеп, "Юк", – диде. Сеңелләремне аякка бастырырга кирәк иде. Мин олы бала идем бит. 43 нче елда әти Харьков янында һәлак булгач, мин гаилә башлыгы булып калдым».



Садри Гарәфиев фотосы





## Иң яраткан фронт фотосы

«Авторы мин булмасам да, бу минем өчен иң истәлекле фотография. Анда миңа, асылда әле малайлыктан да чыгып җитмәгән егеткә, иң зур хәрби бүләкләрнең берсен – "Батырлык өчен" медален тапшыралар. Бу 1945 нче елның июнендә, Берлинны алганнан соң булды. Әлегедәй хәтеремдә, урманда лагерь ясап урнаштык. Тантаналы тезелү булды. Күңел шатлана. Җиңү! Ул хисләрне беркайчан да онытмыйм!»

## Алтын куллы оста

«Бар яктан алдынгы – бу сүзләр минем хакта! Колхозда барлык һөнәрләрне үзләштердем. Балта остасы да, ат караучы да булдым, 50 нче елларда авылга су үткәрдем, электр ялгадым. Колхоз рәисе урынбасары булдым. 1971 елда Дөбъязга күчтем, Дөбъяз авыл хуҗалыгы техникумында укыта башладым».

1948 нче елда туган авылы Яңавылда Садри Гарәфи улы Гарәфиев Рәхилә Ганиевага өйләнә. Алар 49 ел 6 ай бергә яшиләр. Рәхилә ханым алтын туйларын билгеләп үтәргә 6 ай гына калгач, вафат була. Гарәфиевләрнең 5 балалары: 4 улы һәм кызы, 14 оныгы, 9 оныкчыгы бар.



Садри Гарәфиев хатыны Рәхилә белән

